ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР**
**«27» нче август 2020 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 391**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү Тәртибе турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында», 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасының 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы «Контракт буенча муниципаль вазыйфа яки җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында», 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы «Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» Законнары, Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Кушымта итеп китерелгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Биектау муниципаль районының

рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар аны бастырып чыгарган (халыкка җиткергән) көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин

1нче кушымта
Расланган
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Советының
27.08.2020 № 391нче карары белән

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына (алга таба – муниципаль вазыйфа биләүче зат) үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр (алга таба - керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр) тапшырган өчен, әгәр бу мәгълүматларны бозу җитди булмаса, җаваплылык чаралары (алга таба - җаваплылык чаралары) куллану турында карар кабул итү процедурасын регламентлаштыра.

2. 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 40 статьясындагы 7.3-1 өлеше нигезендә керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга карата түбәндәге җаваплылык чаралары кулланыла:

1) кисәтү;

2) муниципаль берәмлек депутатын, җирле үзидарәнең башка сайланулы органы әгъзасын Биектау муниципаль районы Советындагы вазыйфасыннан, муниципаль берәмлек җирле үзидарәсенең бүтән сайланулы органыннан Биектау муниципаль районы Советында, муниципаль берәмлекнең башка сайланулы органында вазыйфа биләү хокукыннан мәхрүм итеп, аның вәкаләтләре чоры тәмамланганчыга кадәр азат итү;

3) даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан аның вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкару хокукыннан мәхрүм итеп азат итү;

4) Биектау муниципаль районы Советында, муниципаль берәмлек җирле үзидарәсенең башка сайланулы органында вәкаләтләре чоры туктатылганчы вазыйфаларны биләүне тыю;

5) вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.

3. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга карата әлеге Тәртипнең 2 пунктында санап үтелгән җаваплылык чараларының берсен куллану турындагы мәсьәлә Биектау муниципаль районы Советында карала (алга таба – Совет).

Әлеге мәсьәләне карау өчен 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 40 статьясының 7.3 өлешендә каралган Татарстан Республикасы Президентының муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турында Советка кергән гаризасы нигез булып тора.

4. Җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президенты гаризасы кергәннән соң өч айдан да соңга калмыйча Совет тарафыннан карала.

5. Совет муниципаль вазыйфаны биләүче затка аңа карата җаваплылык чараларын куллану турындагы мәсьәләне карау хакында күрсәтелгән мәсьәләне карау датасына кадәр кимендә биш эш көне кала язма рәвештә хәбәр итә.

Совет утырышы урыны һәм вакыты турында хәбәр ителгән муниципаль вазыйфаны биләүче затның килмәве Татарстан Республикасы Президентының җаваплылык чараларын куллану турындагы гаризасын карауга комачауламый.

6. Татарстан Республикасы Президентының муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларын куллану турында гаризасы Совет утырышында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2015 елның 02 февралендәге 426 номерлы “Биектау муниципаль районы Регламенты турында” карары (Советның 28.03.2018 N 206, 17.04.2019 N 286 карарлары редакциясендә) белән расланган Совет Регламентында билгеләнгән тәртиптә карала, (алга таба – Регламент).

Күрсәтелгән мәсьәләне караганда муниципаль вазыйфаны биләүче затка тапшырылган белешмәләр буенча аңлатмалар бирү мөмкинлеге бирелергә тиеш.

Муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата җаваплылык чараларының берсен куллану мәсьәләсе каралганда, депутатлар тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу буенча таләпләр үтәлергә тиеш. Совет утырышында рәис депутатларга мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеге турында хәбәр итәргә тәкъдим итәргә тиеш.

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу максатларында мәнфәгатьләр конфликты ягы булган депутат, рәислек итүче тарафыннан карар кабул итүдән читләштерелә.

7. Татарстан Республикасы Президенты гаризасын карау нәтиҗәләре буенча муниципаль вазыйфаны биләүче затка җаваплылык чарасын куллану турында яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турында карар кабул ителә.

Күрсәтелгән карар Регламент билгеләгән тәртиптә кабул ителә.

Аңа карата Татарстан Республикасы Президенты гариза биргән депутат тавыш бирүдә катнашмый.

8. Җаваплылык чараларын куллану турындагы карар, кылынган коррупцион хокук бозу характерын, аның авырлыгын, кылынган хәлләрне исәпкә алып, гаделлек, күләменә туры килү, пропорциональлек һәм котылгысызлык принциплары нигезендә шулай ук муниципаль вазыйфаны, үзенең вазыйфаи бурычларын (вәкаләтләрен) биләүче затның муниципаль вазыйфаны үтәве нәтиҗәләрен, коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән башка чикләүләрне, тыюларны һәм бурычларны үтәвен исәпкә алып кабул ителә.

Хисап чорында керемнәр турында, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен бары тик бер җаваплылык чарасы гына кулланылырга мөмкин.

9. Җаваплылык чарасын куллану турындагы карар үз эченә коррупциячел хокук бозуга, муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан бозылган норматив хокукый актларның нигезләмәләренә, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә карарга карата шикаять белдерү өчен хокукка күрсәтмәләрне үз эченә алырга тиеш.

10. Җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарда мондый баш тартуның дәлилләнгән нигезләмәсе булырга тиеш.

11. Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарның күчермәләре аны кабул иткән көннән алып биш эш көне эчендә муниципаль вазыйфаны биләүче затка имза куйдырып тапшырыла яки тапшыру турында хәбәрнамә белән почта аша җибәрелә, шулай ук Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә.

Җаваплылык чараларын куллану турындагы карарны муниципаль вазыйфаны биләүче затка җиткерү мөмкин булмаса яисә күрсәтелгән имза куеп карар кабул итүдән баш тартса, Биектау муниципаль районы Советы рәисе тарафыннан югарыда күрсәтелгән затның җаваплылык чарасын турындагы карар белән танышудан баш тартуы турында яисә мондый карар турында аңа хәбәр итү мөмкинлеге булмавытурында акт төзи.

12. Җаваплылык чарасын куллану яки җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарга Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирергә мөмкин.